КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 27 гыйнвар г.Казань № б-131

Гражданнар оборонасының һәм Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының идарә органнары, көчләре әзерлеге дәрәҗәсен алга таба күтәрү максатларында:

1. Түбәндәгеләрне (боерыкка теркәләләр) расларга:

2024 елга гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасының төп чаралар планын (алга таба – План);

2024 елга гражданнар оборонасының һәм Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының идарә органнарын, көчләрен әзерләү буенча методик оештыру күрсәтмәләрен.

2. Республика башкарма хакимият органнарына:

Планның үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрүне;

2024 елга гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә төп чаралар планын эшләргә һәм гамәлгә кертергә.

3. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Планның үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрүне;

2024 елга җирле дәрәҗәдәге гражданнар оборонасының, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү системасының һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының идарә органнарын һәм көчләрен әзерләү буенча тиешле методик оештыру күрсәтмәләрен, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә төп чаралар планын эшләүне һәм гамәлгә кертүне.

4. Бу боерыкның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 29 декабрь, б-3023 нче һәм 2023 ел, 23 гыйнвар, б-94 нче боерыклары үз көчен югалткан дип танырга.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин